ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 11** **12 марта 2026 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның 24 декабрендәге
27 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы “Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1994 елның 21 декабрендәге “Янгын куркынычсызлыгы турында”гы 69-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе һава киңлеген файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында”гы 138 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Кәрәкәшле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Кама транспорт прокуратурасының 2026 елның 4 мартындагы 23/1-02-2026 санлы протесты нигезендә һәм беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты **к а р а р б и р ә:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 24 декабрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә пиротехника әйберләрен (фейервер күрсәтүләрен) куллануны тәртипкә салу чаралары турында»гы 27 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 50 метрдан артык биеклектәге салют һәм фейерверклар аттырганда, шулай ук җир яки су өслегенә һава алымнары полосаларын проекцияләү чикләрендә салют һәм фейерверклар биеклегенә карамастан, һава киңлеген куллану Бердәм система оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла ".

1.2. 3,4,5 пунктларын 4,5,6 пунктлар дип санарга

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Рәсми Татарстан» Бердәм дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы М.Н.Мусин